**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора,
Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Кооперативная ур, 5, Биектау т/ю станциясе поселогы,
Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-61, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**05.09.2022 ел** **№ 881**

# Шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарга товарлыклы һәм нәселле таналар һәм бер мәртәбә бозаулаган таналар сатып алуга чыгымнар өлешен каплауга Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү комиссиясе составын раслау турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78 нче статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, 2022 елның 04 апрелендәге 391 номерлы «2022-2024 елларга Биектау муниципаль районы территориясендә шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерү» муниципаль максатчан программасын һәм Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының «2022-2024 елларга Биектау муниципаль районы территориясендә шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерү» муниципаль максатчан программаны раслау турында» Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 04 апрелендәге 391 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 02 июнендәге 556 номерлы карарын, «Шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарга товарлыклы һәм нәселле таналар һәм бер мәртәбә бозаулаган таналар сатып алу чыгымнарының бер өлешен каплауга Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибе турында» 2022 елның 16 маендагы 489 номерлы карарын гамәлгә ашыру кысаларында, КАРАР БИРӘ:

1.Расларга:

1.1. Шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарга товарлыклы һәм нәселле таналар һәм бер мәртәбә бозаулаган таналар сатып алуга чыгымнар өлешен каплауга Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү комиссиясе составын 1 нче кушымта нигезендә.

1.2. Шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарга товарлыклы һәм нәселле таналар һәм бер мәртәбә бозаулаган таналар сатып алуга чыгымнар өлешен каплауга юнәлтелә торган субсидияләр җирле бюджет акчаларыннан нәтиҗәле файдалану буенча комиссия турында нигезләмәне.

3. Әлеге карарны интернет челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ урнаштырып халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары (икътисад буенча) М.Р. Булгаковка йөкләргә.

Биектау муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы Д.Ф.Шәйдуллин

**1 нче кушымта**
Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 05.09 881нче номерлы карары белән расланды

**Шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарга товарлыклы һәм нәселле таналар һәм бер мәртәбә бозаулаган таналар сатып алуга чыгымнар өлешен каплауга Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү комиссиясе составы**

| | |
|---|---|
| Комиссия рәисе | Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе - Хисамутдинов Равил Фәрит улы |
| Комиссия рәисе урынбасары | Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары - Булгаков Мурад Рамил улы |
| Комиссия секретаре | Биектау муниципаль районы башкарма комитетының икътисад бүлеге баш белгече – Адиярова Ләйсән Хәйдәр кызы |
| Комиссия әгъзалары: | Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башлыгы урынбасары – Шакиров Әнәс Шәүкәт улы (килешү буенча) |
| | Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы контроль-хисап палатасы рәисе – Хайрутдинов Наил Фидаил улы (килешү буенча) |
| | Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының икътисад бүлеге башлыгы – Нигъмәтуллина Айгөл Рәшит кызы |
| | Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советының юридик бүлеге башлыгы – Таҗиев Илдар Илгизәр улы (килешү буенча) |
| | Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының финанс-бюджет палатасы рәисе – Вәлиуллина Рамилә Шамил кызы (килешү буенча) |
| | Биектау муниципаль районының авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы - Кәримов Рәхимҗан Зариф улы (килешү буенча) |

**2 нче кушымта**
Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 05.09 881нче номерлы карары белән расланды

**Товарлыклы һәм нәселле таналар һәм бер мәртәбә бозаулаган таналар сатып алуга чыгымнар өлешен каплауга юнәлтелә торган җирле бюджет акчаларыннан нәтиҗәле файдалану буенча комиссия турында нигезләмә**

1. **Гомуми нигезләмәләр**

Товарлыклы һәм нәселле таналар һәм бер мәртәбә бозаулаган таналар сатып алуга чыгымнар өлешен каплауга юнәлтелә торган җирле бюджет акчаларыннан нәтиҗәле файдалану буенча комиссия (алга таба – Комиссия) товарлыклы һәм нәселле таналар һәм бер мәртәбә бозаулаган таналар сатып алуга һәм җирле бюджет акчаларыннан нәтиҗәле файдалануга чыгымнар өлешен каплауга дәгъвачылар заявкаларын карау максатларында төзелгән, ул хуҗалык итүче субъектларга терлекләрнең баш санын саклап калу һәм арттыру эшләрен башкаруда ярдәм итүгә юнәлдерелгән.

2. **Комиссиянең функцияләре һәм бурычлары**

Комиссиянең функцияләре һәм бурычлары түбәндәгеләр:
- Биектау муниципаль районы гражданнарының сатып алынган товарлыклы һәм нәселле таналарга һәм бер бозаулаган таналарга чыгымнар өлешен компенсацияләүгә заявкаларын карау;
- җирле бюджет акчаларыннан нәтиҗәле файдалануны тикшереп тору.

**3. Комиссия вәкаләтләре**

Комиссиягә әлеге Нигезләмәдә каралган билгеле бер критерийлар кысаларында карарлар кабул итү вәкаләтләре бирелде.

**4. Субсидия күләмен билгеләү критерийлары**

Җирле бюджет акчалары исәбеннән субсидияләр «2022-2024 елларга Биектау муниципаль районы территориясендә шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерү» муниципаль максатчан программасын гамәлгә ашыру кысаларында каралган чаралар чикләрендә субсидияләр алучыларга түләнә.

Сатып алуга чыгымнар өлешен каплау күләме:
- товарлыклы таналар һәм (яисә) бер мәртәбә бозаулаган таналар - 30 000 сум;
- нәселле таналар һәм (яисә) бер мәртәбә бозаулаган таналар - 40 000 сум.

Субсидия күләме бер ШЯХка биш баштан артмаган сатып алынган товарлыклы һәм (яисә) нәселле таналар һәм (яисә) бер мәртәбә бозаулаган таналар бәясеннән, транспорт чыгымнарын исәпкә алмыйча, өстәлгән бәягә салымны исәпкә алмыйча, чыгымнарның 70 процентыннан арта алмый.

Комиссия утырышы беркетмә белән рәсмиләштерелә, ул комиссиянең һәр әгъзасы тарафыннан имзалана.

## 5. Йомгаклау нигезләмәсе

Комиссия эшен матди-техник яктан тәэмин итү Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетына йөкләнә.